**Демонстрационный вариант КИМ**

**по учебному предмету родной татарский язык**

**для обучающихся 2 – 9 классов**

# Татар теленнән диктантлар
# (демоверсия)

## 2 нче класс

### Су.

Судан башка яшәп булмый. Без суны эчәбез. Су белән юынабыз. Аның белән аш пешерәбез. Суны сакларга кирәк.(17 сүз)

### Авылда.

Рөстәм җәй көне әнисе белән авылга әбиләренә кунакка килде. Әбисе Рөстәмне шатланып каршы алды. Ул аны тәмле ашлар белән сыйлады.

Рөстәмгә авылда бик ошады.(24 сүз)

### Дус яшибез.

Без яңа йортка күчтек. Монда ишегалды бик зур. Балалар да күп. Кыш көне шуарга тау ясыйбыз. Җәй көне таган бар. Без тату яшибез. Бергә рәхәтләнеп уйныйбыз. (26 сүз)

## 3 нче класс

### Көз.

Менә көтеп алган көз дә килеп җитте. Мәктәпләрдә укулар башланды. Кошлар да җылы якларга очып киттеләр. Кырлар һәм бакчалар бушап калды. Тирә - як сап - сары яфракларга күмелде. (27 сүз)

### Кыш килде.

Көз үтте. Төссез һәм соры көннәр үтеп киттеләр. Яктылык кими бара. Елгалар боз белән капланды. Кошларның күбесе җылы якка китте. Ә кайберләре бездә кышлый. Без кошларга җимлекләр ясадык. Алар безгә рәхмәт әйтер. (32 сүз.)

### Яз ае.

Март – яз ае. Яз көне төннәр кыскара, ә көннәр озыная. Кар эри, тамчылар тама. Җылы җилләр исә. Күктә кояш ныграк кыздыра. Җылы яклардан кошлар да кайта. Тышта бик матур. Мин язны яратам. (32 сүз)

## 4 нче класс

## Тиен.

Тиен – матур җәнлек. Ул урманда яши. Тиен зур түгел. Ул һәрвакыт агачтан агачка сикерә.

Тиен җәй көне кышка азык киптерә. Ул гөмбә, чикләвек ярата. Аның туны да җылы. Шуңа күрә ул салкын көннәрдә дә туңмый.(35 сүз)

## Юл йөрү кагыйдәләрен сакла!

Җәяүлелар бары тик тротуардан гына йөрергә тиешләр. Куркыныч юклыгына ышангач кына юл аша чык. Бары тик светофорның яшел уты янганда гына автомобиль юлы аша чыгарга кирәк. Юл аша чыкканда сөйләшмә.

Транспортка кергәндә ашыкма һәм этешмә.

Беркайчан да автомобиль юллары янында уйнама!

Юл йөрү кагыйдәләрен үтә! (45 сүз.)

## 5 нче класс

## Урманның дусты.

Табигатьнең иң гүзәл почмагы- урманнар. Елның кайсы гына вакыты булмасын, урман безне үзенә тарта. Ләкин урманнарны сакларга кирәк. Урманның дусты агачларны сындырмый, яфракларны өзми. Ул кош ояларын туздырмый. Кошлар урманнарны корткычлардан саклыйлар. Корткычлар агач кайрысын бозалар, яфракларны тишәләр.

Урман дусты урманда ут якмый, янгын чыгармый. (45 сүз)

## Туган ягым кышы.

Декабрь ае кышны башлап җибәрә. Җиргә ап-ак җәймә җәя. Ул агачларны ак шәлгә төрә. Елгаларны көмеш боз белән каплый.

Кыш бабай тәрәзәләрне дә матур бизәкләр белән бизи. Биек кар таулары өя. Шома шугалаклар ясый.

Кар ява, уңыш ява. Кар күбрәк яуган саен, икмәк тә мулрак була. (46 сүз)

## Кошлар концерты.

Туган якларыма яз быел бик зарыктырып кына килде. Килү белән бар дөньяга үзенең сулышын өрде ул. Сыерчыклар, кыр үрдәкләре кайттылар. Алар кайтуга, тирә-юнь ямьләнеп, гүзәлләнеп китте. Сыерчыклар өй кырыйларына, агач башларына кунып оя ясыйлар. Бер кырыйда гына чыпчыклар чыркылдаша. Урамга чыксаң, өйгә керәсе килмәс вакытлар! Көне буена —кошлар концерты... *(50 сүз.)*

**6 нчы класс**

**Авылда.**

Бәләкәй Рөстәм җәй көне әнисе белән авылга әбиләренә кунакка килде. Алар үзләре еракта бер зур шәһәрдә торалар. Рөстәмнең әле беркайчан да авылда булганы юк иде. Авылда әбисе аны бик ягымлы каршылады. Ул аны тәмле әйберләр белән сыйлады.

Рөстәм авылда үзләренең матур шәһәрләре һәм трамвайлары турында сөйләде. Балалар аның сөйләвен рәхәтләнеп тыңладылар. (51сүз)

**Чыршы һәм каен.**

Менә салкын кыш килде. Урман ак кар белән капланды.

Урманда чыршы һәм каен үсә. Чыршы яшел тун кигән, ак мамык шәл ябынган. Аны кышкы җилләр дә куркытмый.

Каен сары күлмәген көз көне үк салган иде. Кыш көне каенга салкын. Аның нәзек ботаклары салкын җилдә калтыраналар. Табигать шундый матур! (51 сүз)

**Туган тел.**

Һәр милләт кешесенең үз туган теле бар. Ул беренче сүзен шушы телдә әйтә. Әнисе һәм әтисе аңа шул телдә эндәшәләр. Әнисе ана телендә бишек җыры җырлый. Дәү әнисе әкиятләр сөйли. Шуңа күрә дә ул телне туган тел диләр. Кеше иң матур сүзләрне шушы телдә ишетә һәм әйтә.

Безнең туган телебез - татар теле. Туган телеңне өйрәнү, үзе зур бәхет ул. (58 сүз)

**7 нче класс**

**Гүзәллек.**

Агачларга карап сокланып туя алмыйм. Миңа агачлар җанлы булып тоела. Аларның яфраклар тибрәтеп сөйләшкәнен ишеткәндәй булам. Алар чыннан да серләшәләр, нәрсәдер сөйләшәләр сыман. Игътибар белән карасаң, бер үк агач ел саен үзенең киемен төрлечә алыштырып тора. Аның яфраклары узган ел тегеләй булса, ә быел алар бөтенләй икенче төрлеләр. Мин гүзәллеккә чумам, алар белән үзем дә сөйләшә башлыйм. (57 *сүз)*

**Кышкы матурлык.**

Кышның җилсез көне. Яфрак-яфрак кар төшә. Ак күбәләктәй кар бөртекләре, куыша-куыша, җир өстенә куна. Күк йөзе болытлы да түгел кебек, әмма ак кар төшә дә төшә.

Кар балаларның алсу битләренә, озын керфекләренә куна. Балалар шуңа бик куаналар.

Нинди рәхәт, нинди матур!

Балалар үзләренең матур чаналарына утырып, таудан шуып төшәләр.

Кыш көне урамнан керәсе килми. Чанага утырып шуасы, чаңгыда йөрисе генә килеп тора. (64 сүз)

**Туган телем.**

Һәр кешенең үзенең туган теле була. Без туган телебезне кечкенәдән үк яратабыз һәм хөрмәт итәбез.

Үзебезнең татар телендә беренче сүз итеп “әни “ сүзен әйткәнбез. Туган телдә беренче бишек җырын ишеткәнбез. Әбиләребез безгә татарча әкиятләр дә сөйләгән.

Мәктәптә без туган телебездә шигырьләр сөйлибез, җырлар җырлыйбыз.

Туган телен яхшы белгән кеше рус телен дә, чит телләрне дә җиңел генә өйрәнә ала. (64 сүз)

## 8 нче сыйныф

## Икмәк – тормыш нигезе.

Кеше икмәксез тора алмый. Без аны яратып ашыйбыз. Хуш исле йомшак икмәк табынга ямь бирә.

Ләкин безнең арада икмәкнең кадерен белми торган кешеләр дә бар әле. Кайчак урамда яки кибет идәнендә ипи кисәкләре ята. Бу кешеләр игенче хезмәтен аңламыйлар булса кирәк.

Игенче йокыдан иртә тора. Ул һаваның төрле шартларында да эштән туктамый. Үстерелгән уңышны вакытында җыеп алырга ашыга. Кызу эш вакытында игенчегә аз гына вакыт ял итәргә кала.

Ипинең һәр валчыгын кадерләргә кирәк. Икмәк - тормыш нигезе.

**Күңелләрдә мәңге сакланыр.**

Бөек Җиңү көне! Бу көнне без сугыш һәм хезмәт ветераннарын чын күңелдән котлыйбыз. Бер минутлык тынлык белән сугыш корбаннарын да искә алабыз.

Мәскәү Кремль стенасы буендагы бакчада батыр солдат кабере бар. Монда күмелгән батырның исемен берәү дә белми. Ләкин бу билгесез солдатның үз-үзен аямыйча сугышып үлүен һәркем хәтерли. Ул башкалабыз өчен барган сугышларның берсендә һәлак була.

Дошман җиңелде. Мәскәүгә үтеп керә алмады.

Менә хәзер шушы кабер өстендә мәңгелек ут яна. Бүтән сугышлар булмасын иде!

## Җәйге ял турында.

Менә безнең көтеп алган ямьле җәй дә җитте. Тиздән җәйге каникуллар башлана. Безне матур, җылы, көләч кояш котлый. Хәзер без дөрес ял турында уйлыйбыз. Иртән көн саен бер үк вакытта торырга кирәк. Көч җитәрлек физик хезмәт тә файдалы. Без су коену һәм кызынуның да чамасын беләбез. Ашарга әзерләргә дә өйрәндек һәм вакытында ашарга да күнектек.

Йокларга да бер үк сәгатьтә ятарбыз. Кызыклы китаплар укырбыз, рәхәтләнеп йокларбыз. Җәйге табигатьне күзәтербез, җиләкләр җыярбыз. Без күңелле ял итәрбез.

**9 нчы сыйныф**

**Туган ягым.**

Туган ягым, туган җирем! Мин синдә туганмын, үскәнмен. Тәмле, шифалы суларыңны эчеп, ләззәтнең нәрсә икәнен татыганмын. Кайчак дымлы, кайчак артык коры туфрагың изгене яманнан аерырга өйрәткән. Кыю, батыр йөрәкле ир-егетләрең хезмәтне сөяргә, туган илне күз карасы кебек сакларга чакыра. Назлы кызларның, сабыр аналарның армас-талмас йөгерек куллары, житез һәм омтылышлы адымнары тормышны сөяргә, киң күңелле булырга өндәп тора.

Туган ягым, туган җирем! Синдә бар нәрсә дә якын, кадерле, газиз миңа.

**Әдәп башы — тел.**

Сөйләгән сүзенә кеше үзе хуҗа. Матур сөйләшергә өйрән. Сөйләгән сүзләрең мәгънәле булсын. Сүзеңне урынсызга сөйләмә. Урынсыз урында сөйләгән сүз яхшы булса да, яман итеп кабул ителер. Файдасыз сүзне дә сөйләмә, чөнки андый сүз үзеңә зыян гына китерер. Акыл ияләре: «Телеңне тик тота белү — сәламәтлек билгесе», — дигәннәр. Кайбер кешеләр сүз аркасында авыруга сабышалар.

Берәү сөйләгәндә, икенчең тыңлап тора. Ул кеше сүзен бетергәч кенә сүзеңне башла. Кеше сүзенә кушылып, аның сүзен бүлмә. Телең татлы, йөзең якты булсын. Татлы телле кешенең дуслары да күп булыр. *(82 сүз.)*